| | |
|---|---|
| ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЮТАЗИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ<br>Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт,<br>423955 |

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» ноябрь 2025 ел № 9

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге составына керүче Екатериновка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 26 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" нигезләмә нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 03 декабрендә 11 сәг. 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Димтамак авыл җирлегенә керүче Екатериновка торак пункты, Яшел урам, 13 санлы торак йорт янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Екатериновка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:

1) 2025 елның 06 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Екатериновка торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында»гы 6 санлы гражданнар җыены карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2) «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенә керүче Екатериновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Екатериновка торак пунктының юл-урам челтәрен һәм поселокка керү юлын норматив хәлгә китерү (реконструкцияләү, ремонтлау, вак таш салу, ПГС салу, ташу, төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге башкарма комитетына Екатериновка торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор)

тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов